СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

11.12.2015 с. Верхний Услон 5-47

Югары Ослан муниципаль районы территориясендә туфракның торышы һәм аны саклау, җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану турында

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының Югары Ослан муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Р.Г. Гобәйдуллинның Югары Ослан муниципаль районы территориясендә туфракның торышы һәм саклануы, җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану турында мәгълүматын тыңлагач,

Югары Ослан муниципаль районы Советы

карар итте:

1. Туфракның торышы һәм аны саклау, Югары Ослан муниципаль районы территориясендә җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- агротехник, урман мелиорациясе, гидротехник, эрозиягә каршы чаралар күреп, җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының Югары Ослан муниципаль районында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын арттыруны һәм саклауны тәэмин итә торган авыл хуҗалыгы формированиеләрен стимуллаштыру мөмкинлеген карау.

3. Авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- авыл җирлекләре территориясендәге бозылган җир кишәрлекләрен рекультивацияләү эшен активлаштырырга;

- авыл җирлекләре территорияләрендәге үз ихтыяҗлары өчен гомумтаралган файдалы казылмалардан файдалану буенча рөхсәт документларын алу эшен дәвам итәргә.

4. Югары Ослан муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына:

- җирдән файдаланучыларның җир хокук бозуларын ачыклау һәм бетерү максатларында җирләрдән файдалануга һәм саклауга муниципаль җир контролен көчәйтергә;

- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белән берлектә Югары Ослан муниципаль районында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге файдаланылмаган җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы әйләнешенә кайтару эшен активлаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, экология, табигый ресурслар һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиатдинов